**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

25.04.2016 Яр Чаллы № 1179

«Экояз» район санитар-экологик конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы һәм Тукай муниципаль районының әйләнә-тирәлегенә сак караш формалаштыру; халыкның хезмәт һәм экологик культурасын тәрбияләү эшендә гореф-гадәтләрен яңарту; яшәү урыннарында чисталык өчен укучыларның социаль җаваплылыгын тәрбияләү, әйләнә-тирәлекне саклау эшендә гражданнар, оешмалар һәм дәүләт хакимияте органнарының гражданнар инициативаларын берләштерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 елның 25 апреленнән 2016 елның 20 маена кадәр Тукай муниципаль районы территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту икеайлыгы (алга таба - икеайлык) буенча район санитар - экологик конкурсын үткәрергә.
2. «Экояз» район санитар-экологик конкурсын үткәрү нигезләмәсен расларга (1 кушымта нигезендә).
3. Район конкурсының жюри составын расларга (2 кушымта нигезендә).
4. Авыл җирлекләре башлыкларына авыл җирлекләре территориясендә «ЭКОяз» конкурсын оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Мәгариф идарәсенә районның гомуми белем бирү учреждениеләре арасында «Экояз"конкурсын оештырырга тәкъдим итәргә.
6. Район халкына, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә район конкурсында актив катнашырга тәкъдим итәргә.
7. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев